| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2018 Казан ш. № 10-187/кс

Җылы белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән бирелә торган кайнар суга 2019 ел өчен тарифлар билгеләү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җылы белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән бирелә торган кайнар суга, шушы карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.
2. Шушы карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан башлап 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2018 № 10-187/кс карарына кушымта

## Җылы белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга «Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән бирелә торган кайнар суга 2019 ел өчен календарь буенча бүленгән тарифлар

| № | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Ел | Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенә компонент, сум/куб.м. | Җылылык энергиясе компоненты | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Бер ставкалы, сум/Гкал | Ике ставкалы | |
| | | | | | Куәт ставкасы, мең сум/ аена Гкал/сәг | Җылылык энергиясе ставкасы, сум/Гкал |
| 1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте* | | | | | |
| 1.1 | Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 24,44 | 1482,63 | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 25,17 | 1527,11 | - | - |
| 1.1.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде) | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 29,33 | 1779,16 | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 30,20 | 1832,53 | - | - |
| 1.2. | Яр Чаллы шәһәре | | | | | |
| 1.2.1 | Кулланучылар | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 30,10 | 1319,16 | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 30,76 | 1349,98 | - | - |
| 1.2.2 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде) | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 36,12 | 1582,99 | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 36,91 | 1619,98 | - | - |

<*> «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте өчен җылылык энергиясен тапшыру матдәсенә җылылык энергиясен тапшыру матдәсенә компонентлар исәпләмәсенә кабул ителә торган тарифлар Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татэнерго» акционерлык җәмгыятеннән кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясен тапшыру матдәсенә 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 17.12.2018 № 5-89/тэ карары белән билгеләнде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге